СОВЕТ ВЕРХНЕОШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с..Верхняя Ошма, д.54 а, с. Верхняя Ошма,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422163

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ УШМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., №54а нче йорт,ЮгарыУшма авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422163

тел.(факс): (85563) 2-32-36; e-mail: Voshm.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар

№ 1-5 «12» январь 2016 ел

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы», «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең «Референдум үткәрү инициативасы турында»2015 елның 18 декабрендәге 11 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советының «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2015 елның 18 декабрендәге 2-4 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советының 2014 елның 02 апрелендәге 2-35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым салу чараларын җыю һәм куллану тәртибе һәм гражданнарның үзара салым салу турында нигезләмә нигезендә статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2016 елның 28 февраленә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби

хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2016 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
Юлга вак таш җәю, грейдер белән тигезләү – 40,0 мең сум
Хасанша торак пунктындагы юлларны вак таш җәеп ремонтлау:
Ленин урамы – 800 м
Чокырларны ремонтлау, грунтовкалау, грейдер белән тигезләү – 40,0 мең сум.
Иске Завод т. п.
Ленин ур. - 800 м.

Комазан урманчылыгы торак пунктында 600 м юлга вак таш түшәргә һәм 40,0 мең сум тигезләргә.

«Әйе» «Юк»

3. Әлеге карарны авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Башлыгы М.Р. Хуҗаҗановка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Югары Ушма авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /М.Р. Хуҗаҗанов/